КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 декабрь г.Казань № 1307

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 апрель, 285 нче; 2014 ел, 11 октябрь, 753 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1084 нче; 2015 ел, 31 декабрь, 1037 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1049 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1094 нче; 2018 ел, 13 июль, 570 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1245 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 743 нче; 2019 ел, 26 декабрь, 1219 нчы; 2020 ел, 29 декабрь, 1224 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1330 нчы, 2022 ел, 19 апрель, 367 нче, 2022 ел, 7 июль, 645 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программага 1 нче кушымтаның «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру өчен

шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү» юлының дүртенче графасында «Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә җирле бюджетлар чыгымнарын планлаштырганда финанс нормативларын билгеләү һәм аларны куллану буенча муниципаль норматив база кабул итү, капиталь характердагы чыгымнардан һәм максатчан чыгымнардан тыш» сүзләрен «Җирле бюджетлар чыгымнарын планлаштырганда белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү (капиталь характердагы чыгымнардан һәм максатчан чыгымнардан тыш) өлешендә муниципаль хокукый актлар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

Программага 2 нче кушымтаның 22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «22. | Җирле бюджетлар чыгымнарын планлаштырганда белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү (капиталь характердагы чыгымнардан һәм максатчан чыгымнардан тыш) өлешендә муниципаль хокукый актлар кабул итү, % | $V_{22} = \frac{A}{B} \times 100\%$,<br>монда:<br>A - хисап елында җирле бюджетлар чыгымнарын планлаштырганда белем бирү программаларынгамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү (капиталь характердагы чыгымнардан һәм максатчан чыгымнардан тыш) өлешендә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары саны;<br>B - Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының гомуми саны | муниципаль хокукый актлар, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының аналитик мәгълүматы». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин